| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НОВОЗАРЕЧЕНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЯҢА ЗАРЕЧЕНСК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2015 нче ел Яңа Зареченск авылы № 19

Яңа Зареченск авыл җирлегенең
2016 елга бюджеты турында

Яңа Зареченск авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1 Статья

1. 2016 елга Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 4818,3 мең сум.;

2) Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4818,3 мең сум.;

3) Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум.

2. 2016 елга Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга;

2 Статья

2017 елның 1 гыйнварына Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә.

2. 2016 елда Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетының муниципаль бурычның иң чик күләмен билгеләргә.

3 Статья

Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетында әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 Статья

1. 3 нче кушымта нигезендә Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген расларга.

2. Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

5 Статья

1. Әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга.

2. 2016 елга Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарның 6 нчы кушымтасы нигезендә бүлүне расларга.

3. Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетының 2016 елга гавами норматив йөкләмәләрне үтәү өчен 0 мең сум күләмендә бюджет ассигнованиеләре күләмен расларга.

6 Статья

1. Җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертларның күләмен раслау, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча төзелгән килешүләр нигезендә, 2016 елга авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итү өчен 2171 мең сум күләмендә җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен, Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертларның күләмен раслау.

2. 2016 елда Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә кирәк.

7 Статья

Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетында Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотацияләрне 2016 елда 2998,4 мең сум күләмендә расларга.

8 Статья

Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетында 2016 елда авыл җирлекләре бюджетларына 5,0 мең сум күләмендә субвенция расларга.

9 Статья

2016 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу өчен Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләрне Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетында расларга.

10 Статья

1. Җирле үзидарә органнары 2016 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны карап тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

11 Статья

Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджеты акчаларының Яңа Зареченск авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2015 елда түләнергә тиешле товарлар, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә калдыклары (статья 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы редакциясендә), 2016 елда Яңа Зареченск авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

12 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Яңа Зареченск авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

13 Статья

1. Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Яңа Зареченск авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Җирлек башлыгы, Яңа Зареченск
авыл җирлеге Советы Рәисе С.Н. Багижева